Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Муниципаль бюджетлы белем бирү учреждениесе
“ Матюшино урта гомуми белем бирү” мәктәбе

| «Каралды» | «Килешенде» | «Расланды» |
|---|---|---|
| Гуманитар фәннәр МБ җитәкчесе | Уку эшләре буенча директор урынбасары | МББУ “Матюшино урта гомуми белем биру мәктәбе” директопы |
| ________Хайдуллова | Шарафеева/Шарафеева/ | Шарафеев/Шарафеев/ |
| 1 нче санлы беркетмә | « 30 » 08 2019 ел | боерык № 1 |
| «26» 08 2019 нчы ел | | « 30 » 08 2019 ел |

# Туган телдән

## 5-9 нчы сыйныфлар өчен

ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Программаны әзерләүче
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
Загирова Раушания Васыйл кызы

Педагогик совет утырышында гамәлгә керде
1 нче беркетмә “ 30 ” 08 2019 ел

2019-2020 уку елы

**Рус төркемендәге 5 нче сыйныф укучылары өчен туган тел (татар теле) буенча белем бирү программасына аңлатма язуы**

***Эш программасы структурасы***

Татар теленең эш программасы түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укытуның планлаштырылган нәтиҗәләреннән.

***Укыту фәненең уку планында тоткан урыны***

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 2 сәгать исәбеннән, елга 70 сәгатькә төзелде.

***Эш программасының эчтәлеге***

***Эш программасының һәм белем бирүнең максаты:***

Татар теленә өйрәтүнең **төп максаты** – **гамәли максат**: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү**. Гомуми белембирү максаты** укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. **Тәрбияви максат** балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

***Бурычлар:***

Гамәли максатка ирешү өчен,укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру; диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү; дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру; татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү.

Гомумдидактик һәм тәрбияви максатларга ирешү өчен, укучыларның акыл хезмәте күнекмәләрен булдыру; татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү; татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һәм татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте турында мәгълүмат җиткерү.

Коммуникатив нигездә татар теленә өйрәтү **гомумдидактик** принципларга (фәннилек, аңлылык, аңлаешлылык, системалылык, эзлеклелек, күрсәтмәлелек, белемне ныклы үзләштерү)**; психологик** принципларга (мотивация булдыру, укучыларның шәхси-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алу); **лингвометодик** принципларга (коммуникативлык, комплекслылык, укытуны телдән алып бару, телгә өйрәтүне гамәли эшчәнлеккә юнәлтү, тел һәм сөйләм күренешләрен сайлау һәм өйрәтүгә функциональ якын килү, тел күренешләрен концентрик рәвештә урнаштыру һәм этапларын өйрәтү, лексик-

грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү, укучыларның ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу) таянып оештырыла.

Гомуми белем мәктәбендә укучыларга татар теленең фонетик, интонацион-прсодик, лексик, грамматик катламнары турында төп мәгълүмат бирелә.

Гомуми белем мәктәбендә грамматикага өйрәткәндә, укучыларның ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу прицибы укытучы игътибарыннан читтә калмаска тиеш, чөнки татар һәм рус телләрендәге сөйләмдә сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйләү закончалыклары күпкә аерылалар; шуңа күрә татар сөйләмендәге иң актив җөмлә калыплары рус телендәге калыплар белән чагыштырылырга, гамәли үзләштерелергә тиеш.

Программа белем бирү учреждениесенең фәннәрне тирәнтен өйрәнү юнәлешле булуын искә алып төзелә. 5 сыйныфта чит телләр һәм рус теле тирәнтен өйрәнелә, шул сәбәпле, программа гамәлдәге базис план буенча атнага 2 сәгать исәбеннән төзелә.

### *5-9 нчы сыйныф укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр*

#### *Тыңлап аңлау*

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

#### *Диалогик сөйләм*

Сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

#### *Монологик сөйләм*

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

***Уку***

Уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;
текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;
таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;
таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

***Язу***

Өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;
конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;
прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;
тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

***Кулланылучы методлар һәм алымнар, технологияләр.***

Аңлы-коммуникатив, репродуктив методлар, эзләнү методы. Мәгълүмати технологияләр, проблемалы укыту технологиясе.

***Укыту-методик комплекты***


1. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар/ Казан: Тат.кит.нәшр., 2011.

2. Программа:Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар) , Казан - 2014
3. Дәреслек: Татар теле 5 нче сыйныф. Хәйдәрова Р.З., Г.М. Ахметзянова. – Казан, “Татармультфильм”, 2014.
4. Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. – Казан: “Яңалиф”, 2004.
5. Дәреслек: Татар теле 5 нче сыйныф. Хәйдәрова Р.З., Белоусова Л.Д., Хәбибуллина Э.Н. – Казан: Мәгариф, 2011.
6. Хәйдәрова Р.З., Г.М. Ахметзянова. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телле балаларның татр теленнән белемнәрен контрольгә алу буенча биремнәр җыентыгы. Яр Чаллы, 2014.
7. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту. 5 нче сыйныф. Укытучылар өчен методик кулланма. Хәйдәрова Р.З., Г.М. Ахметзянова - Казан, “Татармультфильм”, 2014.
8. Рус мәктәпләрендәге рус төркеме укучыларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты, Казан – 2008.
9. Сафиуллина Ф.С. һ.б. Татар теленнән контроль эшләр һәм тестлар. Гомуми урта белем бирүче рус мәктәпләренең 5-11 нче сыйныфлары өчен. – Казан: “Хәтер” нәшрияты, 2003.

*Уку курсының эчтәлеге*

**Без мәктәптә.**

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше. Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат - сан белән төрләнеше. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында зат-сан белән төрләнеше.

**Мин – өйдә булышчы.**

Билгеле үткән заман хикәя фигыль. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Билгеле үткән заманның юклык формасын зат-сан белән төрләндерү.

**Бергә эшлә, бергә аша.**

Инфинив+ булыша төзелмәсе. Минем өчен, безнең өчен..., төрләнеше. “Бу китап аның өчен“ структурасы. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Үткән заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Инфинитив + телим структурасы.

**Ничек эндәшсәң, шулай җавап бирерләр.**

Сыйфатның дәрәҗәләре. Килеш кушымчалары. Аналитик фигыльләр. Боерык фигыль. Телефоннан сөйләшү этикеты.

**Минем туган көнем.**

Булышырга кирәк, чакырырга телим төзелмәсе. Саннар. Кибетнең эш сәгатьләрен әйтә белү. Бәйлек сүзләр. Бәйлек сүзләрнең кулланылышы.

**Минем дустым бар.**

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Сузык авазга тәмамланган исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Билгесез үткән заман. Зат-сан белән төрләнеше. Бәйлек сүзләр.

**Дүрт аяклы дусларыбыз.**

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Күрсәтү алмашлыгының килеш белән төрләнеше.

**Без спорт яратабыз.**

Хикәя фигыль формаларының барлык заманнары.

**Без Татарстанда яшибез.**

Җөмлә төзелеше. Хәзерге һәм үткән заман кушымчалары. Мәгънәдәш сүзләр. Бәйлек сүзләр.

**Светофор – минем дустым.**

Боерык фигыль. Боерык фигыльнең юклык формасы.

**Рус телендә сөйләшүче балаларның татар теленнән белем һәм күнекмәләрен тикшерү төрләре**

**5-9 нчы сыйныфлар**

| | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 5 | 6 | 7 | |
| 1. | Тыңлап аңлау | 0,5-0,7 минут | 0,8-0,9 минут | 1 минут | 1,2 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 5-6 реплика | 6-7 реплика | 7-8 реплика | 9-10 репли |
| 3. | Монологик сөйләм | 7-8 фраза | 8-10 фраза | 8-10 фраза | 10-12 фра |
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуа-тив күнегүләр аша тикшерү | 4 | 4 | 4 | |
| 5. | Уку | 55-60 сүз | 60-70 сүз | 70-80 сүз | 80-90 сүз |
| 6. | Язу: сүзлек диктанты | 8-10 сүз | 10-15 сүз | 15-18 сүз | 18-22 сүз |

Татарстан Республикасы

6кл. Туган тел

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш,** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле укыту системасына да карый. Ягъни, рус телле балаларга татар теле укыту системасының барлык **компонентлары** да: программалар, укыту-методик комплектлары, укыту процессы, белем дәрәҗәсенә контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – **нәтиҗәгә** хезмәт итә.

Тәкъдим ителгән "Гомуми белем бирү мәктәпләрендә рус телле балаларга татар телен комуникатив технология нигездә укыту программасы" психология, педагогика фәннәренең яңа казанышларына таянган һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Әлеге программа рус телле балаларга татар теле укыту буенча **эш программаларын** төзү өчен нигез булып тора. Ул укыту предметының мәҗбүри өлешен билгеләгән төп программага таянып төзелде.

Укытучылар э**ш программаларына** мәктәпнең эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә **сәгатьләр саны бүленешен** һәм материалны **өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә**, **эчтәлекне киңәйтүдә,** шулай ук

укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда **үзгәрешләр** кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының **аңлатма язуында** чагылыш табарга тиеш.

Программа дәүләт контроле һәм белем сыйфатын билгеләү системасы өчен нигез булып тора.

## Татар теле укыту максатлары.

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен укыту **максатлары** берничә аспектны үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.**

*Танып белү максатының эчтәлеге*

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

*Үстерү максатының эчтәлеге*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

*Тәрбияви максатның эчтәлеге*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Татар теленең грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика,

грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

*Белем бирү максатының эчтәлеге*

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

## Коммуникатив технология нигезендә төзелгән программага эчтәлек сайлау принциплары.

Программа Федераль Дәүләт стандартларының методологик нигезе булган **системалы-эшчәнлекле юнәлешкә туры килә торган коммуникатив технологияне** төп укыту ысулы буларак билгели.

Коммуникатив технология нигезендә укыту процессын оештыру өчен, бу технология билгеләгән максатларга һәм принципларга туры килгән программа эчтәлеген сайлау таләп ителә. Димәк, коммуникатив технология нигезендә укыту принципларнын ачыклау – программа эчтәлеген сайлау өчен төп критерийлар, норматив база булып тора.

*1. Телне аралашу аша өйрәнү принцибы*

Атаклы психологлар А.Н. Леонтьев, П.Я. Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнгеч, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашү сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана. Бу процесс түбәндәге схемада күрсәтелә:

**Лингвистик материал сайлау схемасы**

**Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау**
↓
**Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү**
↓
**Сөйләм бурычларын ачыклау**
↓
**Тиешле лингвистик материалны сайлау.**

- Сайлап алынган лингвистик материал филологик формада таныштыргач, аны төрле аралашу сфераларындагы социаль контактларда, аралашу ситуацияләрендә, текстлар эчтәлеген сөйләүдә куллану камилләштерелә. Өйрәнелгән грамматик материал максатчан рәвештә төрле жанрдагы текстлар эчтәлегендә кулланылып, укучыларның сөйләшә алулары камилләштерелә.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал мәктәптә телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

*2. Уку процессын индивидуальләштерү принцибы*

Россия Федерациясенең мәгарифне үстерү доктринасында күрсәтелгәнчә, хәзерге заман белем бирү системасы үсешенең төп юнәлеше – укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру.

Башлангыч сыйныф укучылары эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә, кабул итә һәм фикерли башлый. Күрсәтелгән психологик үзенчәлекләрнең, һичшиксез, эчтәлек сайлаганда исәпкә алынуы зарур.

Башлангыч сыйныфларда укыту процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – лингвистик материалны өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Ассызыклап шуны әйтергә кирәктер, өйрәнелгән лексик-грамматик материал балаларның социаль контактларына туры килеп, аларның татарча аралашуын тәэмин итәрлек булырга тиеш. Әлбәттә, укучыларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

Урта һәм югары сыйныф укучылары өчен программада эчтәлек әхлакый проблемалар тирәсенә туплана. Әйтик, “Белем һәм тормыш” темасында “Яхшы уку өчен, нинди сыйфатлар кирәк?” “Яхшы уку җиңелме?“ проблемалары буенча сөйләшү оештырыла. Аңлашыла: бу әхлакый проблемалар, нигездә, балаларның тормыштагы төрле мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Шунлыктан, укучыларда бу мөнәсәбәтләргә карата үз фикерләрен әйтү, димәк, сөйләшергә теләү ихтыяҗы туа. Укучы, укытучы кушканга түгел, ә үз теләге, үз ихтыяры белән сөйләм эшчәнлегенә тартыла.

*3. Телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы*

Белем алу процессын укучыларның актив фикерләвенә нигезләп оештыру психология һәм педагогика фәннәренең алдынгы вәкилләре куйган төп таләпләрнең берсе. Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә. Шуңа күрә программада һәр сыйныфта аралашу өчен коммуникатив максатлар, өлкән сыйныфларда аралашу проблемалары күрсәтелеп барды. Лингвистик материал һәм сөйләм үрнәкләре программада нәкъ менә коммуникатив максаттан, аралашу проблемаларыннан чыгып билгеләнде.

*4. Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы*

Коммуникатив методикага беренче нигез салучылардан булган Э.П. Шубин мәктәптә чит телне өйрәтү процессында грамматик материалны академик грамматика эзлеклелегендә һәм тирәнлегендә өйрәнүне мәҗбүр итеп куймый. Функциональ принцип нигезендә программага грамматик материал түбәндәге таләпләр буенча сайлана:

- грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә;

– грамматик материалның өйрәнелү тәртибе академик бирелештә түгел, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә;

- грамматик материалның күләме, теоретик авырлыгы укучыларның үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә ала;

- грамматика, тел берәмлеге буларак түгел, ә сөйләм берәмлеге буларак өйрәнелә; иң беренче чиратта, грамматик категориянең формасына түгел, ә аның функциясенә игътибар ителә: хәбәр итү, аңлату, сорау, тәкъдим итү, киңәш бирү, ышандыру һ.б.

Башлангыч этап өчен грамматик материал күрсәтелгән критерийларга таянып сайланды. Берникадәр грамматик материал теоретик формада бирелмичә, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителде. Аларны үзләштерү сөйләм ситуцияләре нигезендә оештырыла. Ә җиңелрәк дип саналган грамматик материал филологик формада, кагыйдәләр нигезендә өйрәнелә бара. Ләкин кагыйдәләрне ятлау мәҗбүр түгел, ә лексик-грамматик материалны күбрәк аралашуда имитацияләүгә игътибар ителә.

Урта һәм югары сыйныфларда – грамматик материал, нигездә, филологик формада, грамматик кагыйдәләр нигезендә тәкъдим ителде.

*5. Ана телен исәпкә алу принцибы*

Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр сыйныфка программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Яңа грамматик кагыйдәләр бары тик ана телендә өйрәнелгәннән соң гына кертелә бара, ә дәреслекләрдә грамматик кагыйдәләрнең рус һәм татар телләрендә бирелүе укучыларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

## Эш формалары:

Сыйныф белән бергә эшләү, группалап, индивидуаль, фронталь, дифференциаль.

**Укыту методлары**: аңлату, проблемалы укыту, тикшерү, әңгәмә, дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү,
биремнәр үтәү.

## Контроль төрләре һәм формалары:

Укучыларныың сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, темаларны үткәннән соң тестлар эшләү.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен 6нчы сыйныфта укытуга 70 сәгать билгеләнә.

VI сыйныф – 2 сәгать – 70 сәгать;

## Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре:**

Урта белем бирү баскычында татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре***:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.
–

## Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре.

### 5-9 нчы сыйныфлар

### Тыңлап аңлау

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

### Диалогик сөйләм

Сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

### Монологик сөйләм

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

**Уку**

Уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

**Язу**

Өйрәнелгән темалар буенча актив кулланууда булган сүзләрне дөрес яза белү;

конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;

тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

## Программаның тематик эчтәлеге

### 6 нчы сыйныф (70 сәг.)

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Яңа уку елы башлана (16 сәг.)** Көз җитте, яңа уку елы башлана. Бу минем мәктәбем. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә тоту. Китаплар дөньясы, китапханәгә бару, китап алу. Китапларга сак караш. | Көз вакытын сурәтли белү. Яңа уку елы башлану, аңа әзерлек, мәктәп турында сөйли белү. Уку-язу әсбапларына сак караш турында сөйләшү. Китапның ни өчен якын дус, киңәшче икәнен сөйли белү. Китапның нәрсә турында, авторы кем икәнен әйтә белү. Китап укырга киңәш бирә белү. Китапханәгә язылу өчен анкета тутыра белү, китапханәдән үзеңә кирәкле китапны сорый, нәрсә турында икәнен сорый, сөйли белү. Китап басылу тарихы турында кыскача белешмә бирә белү. Каюм Насыйри турында кыскача мәгълүмат бирә белү. |
| **Без булышчылар (11 сәг.)** Өй эшләре, өлкәннәргә булышу. Яхшы эшләр. Дуслар белән бергә эшләү. | Өйдә нинди эшләр эшләүнең кирәклеген, нинди эшләр эшләргә яратканыңны, эшләргә теләгәнеңне, ничек булышканыңны сөйли белү. Эшне эшләргә инандыра, ышандыра белү. Кереш сүзләрне кулланып, үз фикереңне раслый белү. Образларга бәя бирә, кешенең характер сыйфатларын әйтә белү. |
| **Дуслар белән күңелле (12 сәг.)** Минем дустым. Чын дус нинди була? Дуслык югалу. Әләкләшү, | “Дус нинди була? Ни өчен дуслашалар? Дуслар бергә нишлиләр? Минем дустым – ул нинди?” проблемалары буенча сөйләшү. |

| | |
|---|---|
| мактану – начар гадәтләр. Дуслар белән бергә ял итү. Кунакларны сыйлау. Туган көн. Төрле рецептлар. | Туган көнгә өстәл әзерләү, өлкәннәргә хөрмәт турында сөйләшү. Әнинең туган көне, аңа булышу турында сөйли белү. Төрле рецептларны сөйли белү. |
| **Туган җирем-Татарстан (13 сәг.)** Туган ил, туган җир төшенчәләре. Татарстанның табигате. Татарстан республикасының дәүләт символлары. Татарстанда яшәүче милләтләр, төрле телләрдә сөйләшү. Халыклар дуслыгы. Татарстанның башкаласы Казан, аның музейлары, театрлары. Татар сәнгатенең күренекле вәкилләре. | Туган ил, туган җир төшенчәләре турында сөйли белү. Россиядәге, Татарстандагы диңгезләрне, елгаларны, шәһәрләрне атый белү. Татарстанның табигатен сурәтли белү. Татарстан республикасының дәүләт символлары турында белешмә бирә белү. Татарстанда яшәүче милләтләр, үзеңнең милләтеңне, нинди телдә сөйләшүеңне әйтә белү. Татарстанда халыкларның дус яшәве турында сөйли белү. Казан шәһәре турында мәгълүмат бирә белү. Татар сәнгать вәкилләренең исемнәрен әйтә белү. |
| **Табигать белән бергә (6 сәг.)** Нәрсә ул табигать? Табигатьнең безгә файдасы. Табигатьне саклау. Кошлар дөньясы. Хайваннар дөньясы. Кыргый хайваннар. Дүрт аяклы дусларыбыз. | Табигать, аның кешеләргә файдасы турында сөйләшү. Кешеләрнең урманга салган зыяны, табигатьне саклау турында киңәшләр бирә белү. Кошлар, хайваннар тормышыннан кызыклы мәгълүматлар сөйли белү. Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре, аларны саклау, карау турында сөйләшү. |
| **Сәламәт тәндә – сәламәт акыл (6 сәг.)** Спорт төрләре. Спорт белән шөгыльләнү. Олимпия уеннары. Сәламәт булу кагыйдәләре. | Спорт төрләре һәм нинди спорт төрләре белән шөгыльләнү турында сөйли белү. Олимпия уеннары, кайда барлыкка килгәнен, нинди уеннар булуын, олимпия уты, олимпия флагы турында сөйли белү. Сәламәт булу өчен, нинди кагыйдәләр үтәргә кирәклеген сөйли белү.<br>Кешенең еш авыру сәбәпләрен әйтә, аңа авырмаска киңәшләр бирә белү. Табибта кай җирең авырту турында сөйләшү. |
| **Светофор – минем дустым (6 сәг.)** Юлда сак булу. Юл йөрү кагыйдәләре. | Ни өчен юлда сак булырга кирәклеген әйтә белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сакларга киңәш бирә белү. |

**7кл. Туган тел**

.

**Туган тел һәм әдәбият укыту максатлары**

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә балаларга туган тел һәм әдәбият укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.**

***Танып белү** максатының эчтәлеге*

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын «бала өчен башка дөньяга тәрәзә ачу» булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

***Үстерү максатының** эчтәлеге.*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

***Тәрбияви максатның** эчтәлеге.*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Туган тел һәм әдәбият грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

***Белем бирү** максатының эчтәлеге.*

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Бурычлар:**

- өйрәнелгән материалга нигезләнгән татар сөйләмен укытучыдан яки башка укучылардан ишетеп аңлау;
- диалогик, монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;
- текстларны сәнгатьле итеп, аңлап укый белү күнекмәләрен булдыру;
- татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү.

Укыту эшчәнлеген оештыру гадидән катлаулыга таба юнәлтелә, 1нче сыйныфта өйрәнелгән грамматик конструкцияләрне системалаштыру, ныгыту, тирәнәйтү бурычы күздә тотыла, укыту балаларның шәхси –психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла.

Укуга өйрәткәндә, рус телле балалар татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтергә, тартыкны сузыкка ияртеп, кыска сүзләрне бөтен килеш, озын сүзләрне иҗекләп укырга, алга таба сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап укырга; укылганның эчтәлегенә төшенеп барырга, яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып күзалларга яки сүзлектән таба белергә тиешләр; кычкырып уку, эчтән уку төрләре кулланыла .

**Укыту предметына гомуми характеристика.**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 нче маддәсе һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы”Закон нигезендә татар һәм рус телләре-тигез хокуклы дәүләт телләре булып тора.Туган телне дәүләт теле буларак өйрәнү телне аралашу чарасы,шулай ук укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү,аларның аралашу культурасын формалаштыру ысулы буларак үзләштерүдән гыйбарәт.Туган телне аралашу чарасы буларак үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар көндәлек тормышта үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булалар.

Туган телне,танып белү чарасы буларак ,укучыларның фикер йөртү,интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә,шулай ук рус телле укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта,башка халыкларга карата хөрмәт хисе,толерантлык,мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәрә.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**

Балаларга туган тел һәм әдәбият укыту предметы, аларның филологик белемнәрен киңәйтә һәм коммуникатив культурасын үстерә.

Татар теле һәм әдәбият укытуга һәр сыйныфта сәгатьләр саны түбәндәгечә каралган:

Туган тел һәм әдәбият укытуга сәгатьләр саны бүленешен, атналык сәгатьләр санын саклаган хәлдә, белем бирү учреждениеләре мөстәкыйль хәл итәләр. Туган тел һәм әдәбият дәресләре ФДББС буенча аерым дәреслекләрдән укытыла.

Укыту планында 7 нче сыйныфта туган тел һәм әдәбиятка атнага 3 сәгать бирелә, 2 сәгать-тел, 1 сәгать-әдәбият вакыт бирелә. Программада 105 сәгать каралган.

**Тел буенча планлаштыра торган контроль эш төрләре.**

|  | Контроль эш - 10 |  | Изложение | Сочинение | Тест | Сүзлек диктанты | Сайланма диктант | Иҗади диктант |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
|  | Язма эш | Диктант |  |  |  |  |  |  |
| 7 | 6 | 4 | 1 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 |

**Предметның эчтәлеге**

| № | Бүлекләр, темалар | Сәг саны | Темага караган төп төшенчәләр | Предмет нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Белем һәм тормыш** | **29 с.** | “Белем һәм тормыш” темасы буенча сөйләргә өйрәнү. Фигыльләрне өйрәнү һәм сөйләмдә куллану | Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшә белү. Начар билгегә үз карашын әйтә белү. Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту, яхшы уку серләре, яхшы уку өчен нинди холык сыйфатлары кирәклеге турында сөйләшә белү. |
| 2 | **Без бергә ял итәбез** | **14 с.** | Буш вакыт турында сөйләшү | Буш вакыт. Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләшү, бәя бирә белү.<br>Яраткан шөгылең турында сөйли белү.<br>Спорт түгәрәкләренә йөрү, спорт уеннарында катнашу, спорт чараларын, тапшыруларын карау турында сөйләшә белү. |
| 3 | **Өлкәннәр һәм кечкенәләр -** | **16с.** | Өлкәннәр һәм кечкенәләр турында сөйләшү. Җөмләнең иярчен кисәкләре турында сөйләшү. | Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы караш турында сөйләшә белү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтә белү, өлкәннәрдән рөхсәт сорый белү. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү, әти-әниләрне бәйрәм белән котлау турында сөйли белү |
| 4 | **Без Татарстанда яшибез** | **15 с.** | Татарстан турында өйрәнү. | Татарстанның табигате, аның табигый байлыклары турында сөйли белү. Туган як табигатенә карата үз фикереңне белдерә белү.Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Атаклы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | композитор Сара Садыйкова турында сөйли белү. |

**Укытуның планлаштырган нәтиҗәләре.**

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятkә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Туган телгә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– «Туган теле» предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

– «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Туган тел һәм әдәбият укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре***:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**
– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**
– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

***Туган теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре***

***Тыңлап аңлау*:**
- төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;
- сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;
- зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;
- сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

***Диалогик сөйләм:***
- сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;
- парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;
- терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә төзеп яза белү;
- татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә һәм яза белү.
-
- ***Монологик сөйләм:***

- программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген язма сөйләмдә бирә белү;
- конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;
- монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;
- өйрәнелгән лексик һәм грамматик берәмлекләрне дөрес кулланып, өйрәнгән текстның эчтәлеген язма сөйләмдә бирә белү;

***Язу:***

- өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;
- конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;
- прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;
- үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру
- тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

**8 кл туган тел**

## 8 нче сыйныф өчен ана теленнән эш программасы

Аңлатма язуы

Уку әсбабы .Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан тәкъдим ителгән Рус телендә гомуми белем бирү мәктәбенең 8 сыйныфы өчен уку әсбабы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Күңелле татар теле, 8 нче сыйныф. — Казан: Татармульфильм, 2014г.

Укыту планында 8 нче сыйныфта ана теле атнага 2 сәгать, елына 70 сәгать яки кимрәк булырга мөмкин.

**Программаның тематик эчтәлеге**

| **Коммуникатив максат** | **Якынча сөйләм үрнәкләре** | **Сүзләр һәм сүзтезмәләр** |
|---|---|---|
| | **Күп укыган – күп белер (12сәг.)** | |
| “Яхшы уку җиңелме?” проблемасы буенча сөйләшү.<br><br>“Яхшы уку һәм яхшы яшәү” проблемасы буенча фикер алышу.<br>Интернет аша үз белемеңне күтәрү турында сөйләшү.<br>Татарстанның Милли китапханәсе турында сөйли белү. | Яхшы уку өчен үзеңә күп таләпләр куярга кирәк: дәрестә игътибарлы булырга, көн дә өй эшен эшләргә кирәк. Өй эшен күчерергә ярамый. <...><br>Яхшы яшәү өчен яхшы уку кирәкме? Минемчә, ... .<br>Син интернет белән дусмы?<br>Рефератка материалны интернеттан алдым.<br>Татарстанның Милли китапханәсе Казанда урнашкан. <...> | Өлгерә, соңга кала, җитешә, иртәрәк, арый, сүз бирә, сүзендә тора, оныта, вакытында, борчыла, тантаналы, узды, бүлек, ялгышты, хәзинә, компьютерлаштырылган, аралаша, килешү, аңлатмалы сүзлек, мәдрәсә, фарсы, гарәп, эзли, эзи, аралашу, чит ил, килешү, сирәк басма, атаклы. |
| | **Мин һәм минем яшьтәшләрем (12 сәг.)** | |
| Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү<br>Яшүсмерләрнең мөнәсәбә-тендә алдашу, ялганлашу кебек күренешләргә үз карашын белдерә белү. | Яшьтәшләреңне хөрмәт итәргә, аларга игътибарлы булырга, ... кирәк, Миңа эшчән кызлар, тәмәке тартмый торган малайлар ошый. <...><br>Ялганлашу – начар гадәт. Җиңү ялганга нигезләнергә тиеш түгел.<br><br>Җәй көне мин хезмәт бригадасында (хезмәт лагеренда) эшләдем.... .<br>“Яшелләндерүчеләр” бригадасында хезмәт хакы зур булды... . Көнлек хезмәт хакы ... | аралашу, ялганлашу, һичшиксез, кызара, хата тану, читләшә, гаеп эзли, ялгышын тану, үпкәләшү, мөнәсәбәт, ялгыз, дәрәҗә, иркен, сөйкемле, тыйнак, ягымлы, сыра, тәмәке, батыр, горур, үз-үзеннән артык канәгать, ант итү, кызыксыну, адым, терелә, көнозын, гарьләнү, елак, көнләшү, чая, кызыксыну, серле, төп роль, хезмәт бригадасы, яшелләндерү, чистарту, хезмәт хакы, гаилә бюджеты, үз өлешем. |

| | | |
|---|---|---|
| Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы, гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары турында сөйләшү.<br>Укучылар арасындагы яшь талантлар турында әйтә белү. | сум иде. Мин гаилә бюджетына үз өлешемне кертергә тырышам...<br>Безнең сыйныфта Оля бик матур җырлый. <… | |
| **Буш вакытымны мин ничек үткәрәм? (12сәг)** | | |
| “Егетлек" проблемасы буенча сөйләшү.<br>Яраткан музыкаң буенча фикер алышу.<br><br>Виртуаль аралашуның төрле ысуллары турында сөйләшү. | Нәрсә ул егетлек? Буш вакытны ничек үткәрү егетлек була ала?<br>Миңа күбрәк татарча рэп ошый. Мин “Иттифак” төркеме белән кызыксынам. <...><br>Минем интернетта үз сайтым, электрон адресым бар. Мин интернеттан файдалы мәгълүматлар алам. <...> | Тәртипсезлек, көчлелек, өлгерлек, егетлек, тупаслык, эшсезлек, башкаручы, иң, әйләнә-тирә, уртак тел табу, эчке дөнья, уен-көлке, игътибар үзәге, читләшү. |
| **Табигать һәм кеше (12 сәг.)** | | |
| Табигатькә сак караш турында сөйләшү.<br>Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү<br>“Яшел планета” конкурсында,<br>Мин чисталык яратам”,<br>“Кошларга ярдәм” акцияләрендә катнашу турында сөйләшү. | Ял иткән урынны чиста калдырырга кирәк, чөнки ... .<br>Чишмәләр изге урын, ял итү урыны, шуңа күрә ...<br>Оксана “Яшел планета” конкурсында беренче урынны алды, чөнки ул ... . | күрәшү, ягулык, учак ягу, чүп-чар, пычрату, чишмә, Җир шары, дым саклау, катнаша, җиңә. |
| **Без Татарстанда яшибез (11 сәг.)** | | |
| Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый | Татарстан Европаның көнчыгышына урнашкан.<br>Казан метросының Г.Тукай тукталышы миңа ошады. <…> | Европа, көнчыгыш, чикләшә, мәйдан, төньяк, көньяк, күмер, бакыр, балчык, бүгенге йөзе, кайсы, |

| | | |
|---|---|---|
| байлыклары турында сөйли белү.<br>Казан шәһәрендәге яңа үзгәрешләр турында сөйли белү.<br>Казанның бүгенге йөзе, архитектура истәлекләре, яңа ял итү урыннары. | Казанда яңа спорт корылмалары төзелде ... .<br>Синң Бауман һәм С-Петербург урамнарының кайсы күбрәк ошый? Без аквапаркта ял итәргә яратабыз, чөнки ... . | оештырыла, истәлек, корылмалары. |
| **Татарстанның күренекле әдипләре (11 сәг.)** | | |
| Габдулла Тукай, Муса Җәлил Абдулла Алиш турында сөйли белү. Аларның шигырьләрен яттан сөйләү.<br>А.Алиш, Галимҗан Ибраһимов турында белешмә бирә белү, әсәрләренең эчтәлеген кыскача сөйләү. | Габдулла Тукай 1886нчы елда мулла гаиләсендә туа. <…><br>Муса Җәлил – Советлар Союзы Герое. <…><br>Абдулла Алиш – Җәлилнең иптәше. | Мәдрәсә, ятим, үги әби, иҗат итә, ачы язмыш, яланаяк, асрарга, олаучы, гаҗәпләнде, кала, күрше авыл, мәкалә, әдәби әсәр, Бөек Ватан сугышы, әсирлек, тоткынлык, көрәш, төрмә, фашизмга каршы, легионерлар, үлемсез, мәңгелек, дан. |

**Программаның эчтәлеге буенча тематик бүленеш**

| № | Темалар | Сәг. саны |
|---|---|---|
| 1 | Күп укыган күп белер. | 12 |
| 2 | Мин һәм яшьтәшләрем. | 12 |
| 3 | Буш вакытымны мин ничек үткәрәм? | 12 |
| 4 | Табигать  һәм кеше. | 12 |
| 5 | Без Татарстанда яшибез. | 11 |
| 6 | Татар халкының күренекле әдипләре турында истәлекләр. | 11 |
| 7 | Барысы. | 70 |

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.**

**Тыңлап аңлау.** Аерым сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү; бәйләнешле текстны тыңлап, эчтәлеге буенча укытучының сорауларына җавап бирү; дәрес барышында җанлы сөйләмне аңлап аралаша белү, фикер алышуда катнашу.

**Диалогик һәм монологик сөйләм.** Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү, аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү; парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү; терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү. Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү; конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү.

**Уку.** Танышу, өйрәнү һәм карап чыгу максаты белән уку төрләреннән файдаланып, текстларны аңлап уку һәм кирәкле мәгълүматны табу; укылган текстның эчәлеген кыскача яки тулы итеп сөйләп бирү.

***Белемнәрне тикшерү төрләре***

| Чирек | Сәгатьләр саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | тестлар | Барлыгы |
| 1чирек | | 2 | 1 | 3 |
| 2 чирек | | 1 | 1 | 2 |
| 3 чирек | | 3 | 1 | 4 |
| 4чирек | | 2 | 1 | 3 |
| Барлыгы | | 8 | 4 | 17 |

**Балаларның белем һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары.**

**Тест эшләрен бәяләү нормалары**

Тест эшләре түбәндәгечә бәяләнә. Әгәр укучы бирелгән эшнең

90 - 100 % башкарса “5” билгесе куела,

70 - 89 % башкарса “4” билгесе куела,

50 - 69 % башкарса “3” билгесе куела,

50 % түбән булган очракта “2” билгесе куела

**Диалогик сөйләмне бәяләү**
Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, «5»ле куела.
Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча репликаларның әйте¬лешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2 — 3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, «4»ле куела.
Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4 — 6 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлексез диалогик сөйләм төзегәндә, «3»ле куела.
Бирелгән ситуаиия яки лексик тема буенча диалог төзи алмаганда, «2»ле куела.
**Монологик сөйләмне бәяләү**
Әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен «5»ле куела.
Аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки жөм¬лә төзелешендә 2 — 3 хатасы булган, эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм өчен «4»ле куела.
Сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4 — 6 хаталы, эчтәлеге ягыннан эзлекле булмаган монологик сөйләм өчен «3»ле куела.
Лексик темага монолог төзи алмаганда, «2»ле куела.
**Ишетеп аңлауны бәяләү**
Тыңланган татар сөйләмен тулаем аңлап, төп эчтәлеген сөйләп бирә алганда, «5»ле куела.
Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алганда, «4»ле куела.
Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйли алганда, «3»ле куела.
Тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда, «2»ле куела.
**Укуны бәяләү**
Текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле итеп укыганда, «5»ле куела.
Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, әмма 2—3орфоэпик хата (авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, интонацияне сакламау) булганда, «4»ле куела.
Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда, 4 — 6 тупас орфоэпик хата булганда, «3»ле куела.
Текстның эчтәлеген тулысынча аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләр¬не бозып укыганда, «2»ле куела

**Йомгаклау билгесе:** Йомгаклау билгесе чирек, яртыеллык һәм уку елы ахырында куела. Ул , беренче чиратта, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләре,бәйләнешле сөйләм төзи белә осталыгы,татар телендә аралаша алу мөмкинлекләреннән чыгып, шул ук вакытта язма эшләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алып куелырга тиеш.

**Туган тел  һәм әдәбият  9кл**

1 Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы (Төзүче-авторлары: Р. З. Хәйдәрова,К. С. Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова), Казан, 2013 нче елы

## Туган тел һәм әдәбият укыту максатлары

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә балаларга туган тел һәм әдәбият укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.**

***Танып белү*** *максатының эчтәлеге*

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын «бала өчен башка дөньяга тәрәзә ачу» булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

***Үстерү максатының*** *эчтәлеге.*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

***Тәрбияви максатның*** *эчтәлеге.*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Туган тел һәм әдәбият грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

***Белем бирү*** *максатының эчтәлеге.*

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Бурычлар:**

- өйрәнелгән материалга нигезләнгән татар сөйләмен укытучыдан яки башка укучылардан ишетеп аңлау;

- диалогик, монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;

- текстларны сәнгатьле итеп, аңлап укый белү күнекмәләрен булдыру;

- татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү.

Укыту эшчәнлеген оештыру гадидән катлаулыга таба юнәлтелә, 1нче сыйныфта өйрәнелгән грамматик конструкцияләрне системалаштыру, ныгыту, тирәнәйтү бурычы күздә тотыла, укыту балаларның шәхси –психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла.

Укуга өйрәткәндә, рус телле балалар татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтергә, тартыкны сузыкка ияртеп, кыска сүзләрне бөтен килеш, озын сүзләрне иҗекләп укырга, алга таба сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап укырга; укылганның эчтәлегенә төшенеп барырга, яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып күзалларга яки сүзлектән таба белергә тиешләр; кычкырып уку, эчтән уку төрләре кулланыла

**Укыту предметына гомуми характеристика.**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 нче маддәсе һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы”Закон нигезендә татар һәм рус телләре-тигез хокуклы дәүләт телләре булып тора.Туган телне дәүләт теле буларак өйрәнү телне аралашу чарасы,шулай ук укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү,аларның аралашу культурасын формалаштыру ысулы буларак үзләштерүдән гыйбарәт.Туган телне аралашу чарасы буларак үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар көндәлек тормышта үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булалар.

Туган телне,танып белү чарасы буларак ,укучыларның фикер йөртү,интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә,шулай ук рус телле укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта,башка халыкларга карата хөрмәт хисе,толерантлык,мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәрә.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**

Балаларга туган тел һәм әдәбият укыту предметы, аларның филологик белемнәрен киңәйтә һәм коммуникатив культурасын үстерә.

Татар теле һәм әдәбият укытуга һәр сыйныфта сәгатьләр саны түбәндәгечә каралган:

Туган тел һәм әдәбият укытуга сәгатьләр саны бүленешен, атналык сәгатьләр санын саклаган хәлдә, белем бирү учреждениеләре мөстәкыйль хәл итәләр. Туган тел һәм әдәбият дәресләре ФДББС буенча аерым дәреслекләрдән укытыла.

Укыту планында 9 нчы сыйныфта туган тел һәм әдәбиятка атнага 3 сәгать бирелә, 2 сәгать-тел, 1 сәгать - әдәбиятка вакыт бирелә. Программада 105 сәгать каралган.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга Әдәбият укытуның максатлары һәм бурычлары**

**-укучыларның гомуми белем** мәктәбендә үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү һәм тирәнәйтү;

- тел күренешләрен танып белергә, чагыштырырга,гомумиләштерүгә күнектерү;
-татар телен халыкның рухи,әхлакый,мәдәни хәзинзсе буларак аңларга ирешү;
- татар әдәбиятыннан алган белемне сөйләм телендә куллана белү;
- алган белемнәрне җанлы аралашу шартларында кулланырга өйрәтү;
-укучыларның орфографик, пунктуацион грамоталылык дәрәҗәсен камилләштерү.

Укыту планында 9 нчы сыйныф та татар әдәбиятыннан атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Татар әдәдбиятыннан тематик планны”Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”на нигезләнеп төзедем. Программада 34 сәгать каралган. Авторлары Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева К.,2011

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы**

**Тыңлап аңлау**.Укучыларның җанлы сөйләмне тыңлап аңлау күнекмәләрен камилләштерү; тыңлаган мәгълүматка нигезләнеп,күмәк аралашуда катнашу.

**Сөйләү**.Аралашу барышында коммуникатив максатка ирешү һәм үз фикерләрен эзлекле итеп белдерү; тормыштагы вакыйгалар,күренешләр турында хәбәр итү һәм фикер йөртү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген мөмкин кадәр эзлекле һәм аңлаешлы итеп сөйләү.

**Уку**.Танышу,эзләнү,өйрәнү,карап чыгу максаты белән уку төрләреннән файдаланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку һәм интернет аша кирәкле мәгълүматны табып уку күнекмәләренә иябулу; укылган текстның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләп бирү;

**Язу һәм язма сөйләм**.Бәйләнешле текстларны рус теленнән татарчага тәрҗемә итү; тәкъдим ителгщн тема буенча чыгыш ясау цчен тезислар язу; аралашу ситуацияләрендә сөйләм үрнәкләреннән һәм гыйбарәләреннән файдалану.

**Укыту-методик комплекты**

1. Р.З.Хәйдәрова.”Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технологиянигезендә укыту программасы”К.2011
2. Рус мәктәпләрендәге рус төркеме укучыларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты
3. Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева”Татар теле”урта гомуми белем бирүче мәктәпнең рус телле укучылар өчен 9 нчы сыйныф дәреслеге

**Туган телне укыту эчтәлеге (барысы 70 сәг.)**

**Без Татарстанда яшибез(25 сәг.)**

“Татарстан республикасы” текстындагы лексик-грамматик материал.”Тарихи башкала” текстында лексик-грамматик материал. “Татар музыка сәнгате”. “сәнгать дөньясында” текстында лексик-грамматик материал. Исем фигыль. “Татар театры”текстында лексик-грамматик материал. Текст өстендә эшне дәвам итү. Теләк белдерү формалары. Сыйфат һәм сыйфат дәрәҗәләре. Алмашлык төркемчәләре. Сан һәм аның төркемчәләрен искә төшерү. Ярдәмлек сүз төркемнәре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Иярчен кисәкләр(аергыч,тәмамлык,хәл).Кушма җөмлә, аның төрләре белән танышу.Хикәя фигыльнең заман формалары. Теркәгечләр. Сыйфат фигыль. “А.Ключарев” текстындагы лексик-грамматик материал. Х.Якупов турында белешмә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Иярченле кушма җөмлә. Ситуатив күнегүләр,тәрҗемә итү.

**Һөнәр сайлау ( 13 сәг.)**

Сүз ясагыч кушымчалар. Һөнәр темасынакараган сүзләр.Иярчен җөмлә. Иярченле хәбәр җөмләләр. Иярчен аергыч җөмләләр. Иярчен тәмамлык җөмләләр. Шарт фигыль.Иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә. Килешләрне искә төшерү. Тезүче һәм ияртүче иеркәгечләр. Ияртүче һәм тезүче теркәгечләр. Иярчен урын җөмлә. Иярчен максат җөмлә. Икмәккә хөрмәт турында әңгәмә.

**Сәламәтлек-зур байлык( 5 сәг.)**

Инфинитив. Исем фигыльнең килешләр белән төрләнеше( барлыкта, юклыкта). Теләкне белдерү формасы.Сәламәтлекне саклау – зур бурыч. Телефон, гаджетлар турындагы текстта лексика.

**Беркем дә,бернәрсә дә онытылмый ( сәг.)**

Бөек ватан сугышы безнең күңелләрдә лексик-грамматик материал. “Әсирлектә туган дуслык”текстында лексик-грамматик материал. Сан,сан төркемчәләре.”Җәлилчеләр”тексты белән танышу,тәрҗемә күнегүләре, сорауларга җавап. Кабатлау күнегүләре. Очучы Мәгүбә Сыртланова турында” лачын кыз” хикәясеннән өзек. Лачын кыз” хикәясендә лексик-грамматик материал. Сугышта күрсәткән батырлыклар . күнегүләр өстендә эш. Г. Ә псәлләмовның “Газинур”әсәрендә лексик-грамматик материал. “Газинур” романы аша диалогик-монологик сөйләмгә чыгу. Кабатлау күнегүләре. Инфинитив + кирәк формасы. Табигатькә сакчыл караш.”Табигатьне саклау “ тексты өстендә эш. Иярчен сәбәп җөмлә. Карточкалар белән эш. Иярчен кире җөмлә. Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Саннарны кабатлау. Б.с.т.ү. картина буенча хикәя язу. Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗаты. Ситуатив күнегүләр, тәрҗемә итү күнегүләре. “ бөек ватан сугышының75 еллыгына сөйләшү. Карточкалар белән эш. Текст аша диалогик, монологик сөйләмгә чыгу. Уку елын йомгаклау буенча контроль эш (ситуатив күнегүләр).хаталар өстендә эш. Кабатлау күнегүләре. Казанга экскур ция. Йомгаклау дәресе

Прошито,
Пронумеровано и скреплено печатью
46 страниц
Директор МБОУ «Матюшинская СОШ»:
________
И.А.Шарафеев